Хәмидуллина, Р. Чаллыда беренче китапханә кайчан ачылган / Р. Хәмидуллина // Шәһри Чаллы. – 2025. – №38 (28 май). – Б. 5.

# Чаллыда беренче китапханә кайчан ачылган?



**Китапханә - ул уку йорты. Беренче китапханәләр «көтебханаләр» дип йөртелгәннәр. Көтебхана исламия - Казанда беренче татар китапханәсе. Рәсми төстә 1906 елның 2 гыйнварында ачыла. Оештыручысы - Әхмәтхади Максуди (1867-1941). Китапханә башта «Болгар» мосафирханәсенең бер бүлмәсендә урнаша. Аннан соң Кабан күле буенда аерым йортка күчерелә, шунда уку залы да 1922 елның маеннан ул Мулланур Вахитов исемендәге «Шәрекъ» көтебханәсе дип атала башлый. Соңыннан совет чорында, китапханәнең гарәп хәрефе белән басылган китап фонды казан университетының гыйльми китапханәсенә күчерелә.**

Яр Чаллы төбәге тарихына күз салабыз икән беренче мәдәни-агарту учреждениесе буларак, 1904 елның декабрендә А. С. Пушкин исемендәге җәмәгать китапханәсе ачыла. Ул Кама ярындагы Үзәк урамында урнашкан сәүдәгәр Баутинның чәйханәсе коридорында эшли башлый. Китап, газета-журналлар сатып алу өчен земство елына 300 сум акча бүлеп бирә. Китапханә турында кайгыртуны химаяче (попечитель) Иванов үз өстенә ала. Бу хезмәт өчен түләү булмаганлыктан анда аерым кешеләр генә дежур тора.

Китапханә зур өзеклекләр белән эшли, ә 1908 елның 13 августыннан 1909 елның 13 декабренә кадәр ябылып та тора. 1910 елда китапларны җирле табибның хатыны Л.Ф. Чуфарская кабул итеп ала. Акт буенча 755 җшэ китап, 304 данә вакытлы матбугат басмалары кабул ителә. Китапханәнең бюджеты елга 600 сум тәшкил итә. Китапханәченең еллык хезмәт хакы - 180 сум, җыештыручыга 72 сум түләнә, бюджетта каралган калган акчалар бина өчен, яктылык, ягулыкка түләргә, китап, газета-журналлар алырга карала. Л.Ф. Чуфарская еллык эш хисабында спектакльләр куеп, бюджетны 134 сум 63 тиенгә тулыландырганын күрсәтә. Бу акчага 224 данә зурлар һәм балалар китаплары сатып алына, газета-журналларга язылу үткәрелә. Ел азагында 475 китап укучы теркәлә, аларның 270е балалар була.

Бөтенроссия Үзәк башкарма комитеты Декретлары нигезендә, 1920 елның 27 маенда РСФСР составында Татар Автоном Совет Социалистик Республикасы төзелү татар мәдәнияте үсешендә, шулай ук китапханәләр эшендә зур үзгәрешләр алып килә. Ул вакыттагы матбугат битләрендә эшчеләр һәм крестьяннарның яңа китапханәләр булдырулары, аларның эшчәнлегендә актив катнашулары турындагы мәгълүмат бик еш очрый.

1920 елда Минзәлә өязе составындагы Чаллы кантоны Татария составына керә. Җирле пропаганда бүлеге кантон китапханәләр челтәрен, халык йортларын һәм клубларын яңадан карауга керешә. Китаплар җитмәү һәм аларны сатып алуга акча булмау, әзерлекле белгечләр җитмәү аркасында, 1921 елның 1 декабреннән Чаллы кантоны мәдәни-агарту учреждениеләре, китапханәләр челтәрен киметергә мәҗбүр була. 19 китапханә, 90 уку йорты (изба-читальня), 14 халык йорты калдырыла, ә калганнарына үз хисапларына яшәргә тәкъдим ителә.

1940 елларга кадәр китапханәләр «уку йорты», «Изба - читальная» лар дип йөртелгәннәр. Аннан соң гына китапханәләр дип үзгәртелә.

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА,**
**китапханәче, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре**

**ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕ**

Китапны кайдан алдың, шунда куй.
Китапның белмәгәне юк.
Китап - тормыш көзгесе.
Китап - белем чишмәсе.
Китап - галим, телсез мөгаллим.
Тәгам тән үстерә, китап күңел үстерә.
Алтын җирдән табыла, акыл - китаптан.
Акылың юлбашчың булсын, китап юлдашың булсын, белемең киңәшчең булсын.
Укысаң - белерсең, укымасаң - белерсең.
Укысаң - узарсың, укымасаң - тузарсың.
Уку каты булса да, җимеше татлы.

**КҮРЕНЕКЛЕ КЕШЕЛӘР СҮЗЛӘРЕ**

Фәлсәфәче, акыл иясе Аристотель: «Китапханә-ул ъәрбе- ребез өчен тудырылган өстәл, анда һәркем үзенә кирәкле азыкны таба ала».
Шагыйрь, мөгаллим, публицист Сәгыйть Рәмиев:
«Акылга нур биргән - уку»,
«Безне адәм иткән - уку».
«Адәмне алга илткән - уку».
«Йөзне дә ак иткән - уку».
«Сүзне дә хак иткән - уку».